КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 25 гыйнвар № 25

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 октябрь, 788 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1055 нче, 2015 ел, 1 апрель, 203 нче; 2015 ел, 10 октябрь, 758 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның 7 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

4.5.13 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга проектлар сайлар алу тәртибендә:

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Проектларны сайлап алу елына кимендә дүрт тапкыр үткәрелә. Сайлап алу турында мәгълүмат проектларны сайлап алу башланган датага кадәр кимендә 10 эш көне алдан «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» дәүләт автоном учреждениесенең (алга таба – «ИТ-парк» ДАУ) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) урнашкан рәсми

сайтында урнаштырыларга тиеш. Заявкалар кабул итү проектларны сайлап алу башланган көнгә кадәр бер эш көне алдан тәмамлана.»;

8.1 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проектларны сайлап алуның беренче этабын үткәрү вакыты өч эш көненнән артмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\25.docx